РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«14» ноябрь, 2025 Олы Кайбыч ав. № 17

2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фаразы турында

Татарстан Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары О.Д. Макарованың «2026-20283 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» докладын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фаразы турында мәгълүматны (кушымта) игътибарга алырга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталы»нда һәм Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга: http://kaybici.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Н.Макаровка йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгы А.И. Рәхмәтуллин

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының
2025 е. «14» ноябрь 17 номерлы
карарына кушымта

**Кайбыч муниципаль районының параметрлары якындагы өч елга бюджет проекты нигезенә салынган социаль-икътисадый үсеш фаразы**

Фараз Кайбыч муниципаль районындагы алдагы чордагы социаль-икътисадый вазгыятьне һәм агымдагы елда көтелгән үсеш йомгакларын анализлау нигезендә эшләнгән.

Фараз проектын эшләү РФ Икътисади үсеш министрлыгы тәкъдим иткән уртача-оптимистик вариант нигезендә гамәлгә ашырылды. Кайбыч муниципаль районы буенча фараз күрсәткечләрен эшләү өчен Татарстанстат, шулай ук район предприятиеләре белешмәләре нигез булды.

Районның социаль-икътисадый үсеш фаразына ярашлы рәвештә, 2026-2028 елларда түбәндәге төп күрсәткечләргә ирешергә кирәк:

- 2025 ел йомгаклары буенча 6 миллиард 573 миллион сум тәшкил иткән **тулай территориаль продукт күләме** узган елга карата7,4% үсеш белән.

2026 елга 7,1 млрд. сум (алдагы елга карата 107,5%) фаразлана, алга таба үсеш 106 шар %. ТР буенча тулай төбәк продукты якынча 5, 8 трлн. сум булыр дип көтелә, үсеш темпы 102,1%.

- 2025 елга үз производствосының төяп җибәрелгән товарлар күләме 636 млн. сумнан артык каралган. (факт 2024 ел, 900 млн. сум). Алга таба «Ярателькорм» ҖЧҖ катнаш азык күләмен районыбызга керткәндә 5,2 һәм 6,2 % үсеш белән.

Предприятиеләрнең планнарын гамәлгә ашыруны исәпкә алып, сәнәгать җитештерүе индексы 101% дәрәҗәсендә планлаштырыла ( Татарстан Республикасы буенча план 101,7-102,2%).

Район икътисадының өстенлекле юнәлеше - аграр тармак. Гомумән алганда, агымдагы ел авыл хуҗалыгы өчен уңышлы булды. 2025 елда авыл хуҗалыгы предприятиеләре һәм район халкы тарафыннан җитештерелә торган авыл хуҗалыгы продукциясе күләме 4,5 млрд. сумга (2024 елга карата 115,7%) көтелә, алга таба - 110,7; 108,7 һәм 107,3 %. (Татарстан Республикасы буенча фаразлана торган елларга үсеш темплары 101,5-101,7 %).

Авыл хуҗалыгы күрсәткечләрен үстерү өчен барлык юнәлешләр дә актуаль. Бу эре авыл хуҗалыгы оешмаларын да, фермер хуҗалыкларын да һәм гражданнарның шәхси хуҗалыкларын да үстерү.

Икътисадта алга таба үзгәрешләрнең нигезе - инвестицияләр. Безнең бәяләүләр буенча төп капиталга инвестицияләр күләме агымдагы елда 2,7 млрд.

сум тәшкил итәчәк. 2026 - 2028 елларга инвестицияләр күләме динамикасы 106,4% дәрәҗәсендә фаразлана; 105,4%; 105,3%. (ТР буенча 106,0%).

Инвестиция проектларын гамәлгә ашыру фаразны тәэмин итүнең төп факторларының берсе булып тора. Агымдагы елның 23 маенда «муниципаль сәгать»дә Инвестиция үсеше агентлыгында районның инвестиция· потенциалы республиканың бизнес-җәмәгатьчелегенә тәкъдим ителде. Хәзерге вакытта берничә перспектив проект эшли.

М12 югары тизлекле автомагистрален файдалануга кертkәннән соң «Кайбыч-Логистик» ҖЧҖ инвесторы җәлеп ителде. Якын арада логистик үзәге булган шәхси сәнәгать паркы төзү планлаштырыла. Инвестицияләрнең гомуми күләме 10,4 млрд. сум тәшкил итәчәк. Беренче этапта 2 резидент урнаштыру һәм 300 эш урыны булдыру каралган.

«Август-Кайбыч» җәмгыяте авыл хуҗалыгы җитештерүенә инвестицияләр кертүне дәвам итә. Быел Кичкеево авылы янындагы 644 гектар мәйданда сугару системасы төзелеп бетте, әлеге юнәлеш буенча инвестицияләрнең күләме - 400 млн сум.

Бүгенге көндә «Туган як-Агро» ҖЧҖ сөтчелек комплексының икенче чиратын төзи, бу, предприятиенең җитештерү куәтләрен сизелерлек киңәйтеп, гомуми баш санын 988 башка җиткерергә мөмкинлек бирәчәк.

Ярател компаниясе «Ак Барс» кошчылык комплексы өчен сәгатенә 45 тонна җитештерүче, гранулалы һәм вакланган терлек азыгы җитештерү буенча модульле катнаш азык заводы төзеп бетерде. Проект буенча инвестицияләр күләме 1,5 млрд. сум тәшкил итә.

Инвестицияләр күләме үсеше шулай ук республика һәм федераль программаларда һәм милли проектларда катнашу исәбенә тәэмин ителәчәк. Агымдагы елда район 18 республика һәм федераль программасында, шул исәптән 6 илкүләм проектта катнаша.

Районыбыз икътисадына инвестицияләр җәлеп итү - стратегик бурычларның берсе. Инвестицияләр үсеше бюджетка салым кертемнәрен арттыруга, яңа эш урыннары булдыруга гына түгел, безнең халыкның тормыш дәрәҗәсенә һәм сыйфатына да турыдан-туры йогынты ясый. Шуңа күрә безгә эшмәкәрләр эше өчен уңайлы шартлар тудырырга һәм районыбызның җәлеп итүчәнлеген арттыруга юнәлтелгән уңайлы инвестиция климаты булдырырга кирәк.

Халыкның ихтыяҗларын тәэмин итүнең төп сегментларының берсе - кулланучылар базары. Ваклап сату әйләнеше 2025 елда 1,8 млрд. сум дәрәҗәсендә көтелә, ягъни шул ук чорга карата 109,7%, һәм фаразлана торган чорларга 106,1; 105% (Татарстан Республикасы буенча үсеш темпы 107%). Бизнесны хуплый торган чаралар комплексы кабул ителде. Бәяләр мониторингы һәм беренче зарурлык товарлары булу гамәлгә ашырыла. Сәүдә челтәрләрендә халык өчен кирәкле барлык азык-төлек товарлары бар, аларнгы кайтару эш режимында дәвам итә.

Тиздән Колаңгы станциясендә «Верный» азык-төлек супермаркеты төзеләчәк. Төзелеш башлану вакыты - агымдагы елның ноябрь ахыры, ә киләсе елның апрелендә ачарга планлаштыралар. Эшкә якынча 10 хезмәткәр кабул ителәчәк. Төзелеш вакытында 25 млн. сум инвестицияләр салынган , моннан тыш кибет ачу өчен якынча 20 млн. сум кертәчәкләр (җиһазларны да кертеп).

Социаль-икътисадый үсешне тәэмин итү өчен кече һәм урта эшкуарлыкка мөһим роль бирелә.

Агымдагы елның 1 ноябренә районда 294кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты ( +22, шундый ук чорга- 272) теркәлгән, план 254, үтәлеше - 107,1%. 874 үзмәшгульл теркәлгән, аларның 84 % һөнәри керемгә салымны (Татарстан Республикасы буенча - 72%) актив түләүче булып тора.

Соңгы елларда район икътисадына кече бизнес кертүнең уңай динамикасы күзәтелә.

Район үзәгендә Гыйсмәтуллиннар гаиләсе 120 кешелек банкет залы төзеде. «Авылча ит - мясо по деревенски» сәүдә ноктасы ачылды.

Яз көне Хуҗа Хәсән авылында Канашовлар гаиләсенең яңа кибете эшли башлады.

Районда туризмны үстерүгә игътибар бирелә башлады. Балыкчылык белән бәйле барлык төр туризмның потенциалы зур.

Балык хуҗалыгы территориясендә кунак йортлары төзеделәр, бу туристларны җәлеп итәргә ярдәм итте. Быел хуҗалык хезмәтләреннән 12 меңгә якын кеше файдаланды. Планда - балыкчылык урыннарын киңәйтү өчен күрше буаны чистарту, яңа 10 кунак йорты төзү.

Киләсе елда эшкәртү цехы, кибет һәм юл буе кафесы төзергә телиләр. Ысланган балык, шулай ук үз кибете аша сатылачак балык яки үз кафесында тәкъдим ителәчәк әзер балык булыр дип өметләнәбез.

«АртСад» КФХ 119 гектар җирдә җиләк-җимеш культуралары үстерү белән уңышлы шөгыльләнә. Хуҗалык ассортиментында кара карлыган, кура җиләге, күк җиләк һәм бакча җиләге, шулай ук элиталы сортлы бәрәңге үстерделәр; ике зур теплица төзергә телиләр.

Хисап елында «Агротуризм» федераль программасы буенча грант оттылар, аның акчасына «Ягодное королевство» инновацион туристик глэмпинг комплексы төзиләр.

Елга ярларын төзекләндерү, беседкалар, балыкчылар өчен пирс, мунча комплексы, балалар һәм актив ял итү мәйданчыклары, ял итү зоналары төзү күздә тотыла.

КФХ башлыгы Сайранов гаилә ял итү һәм күңел ачу үзәген төзүне планлаштыра, проект документациясе әзерләнгән.

Шулай итеп, максатчан параметрларга ирешүнең төп факторлары яңа КУЭ булдыруны стимуллаштыру һәм аларның сыйфатлы үсешен тәэмин итү исәбенә КУЭ субъектларына күрсәтелә торган ярдәмнең колачлануын һәм күләмен арттыру эшкуарлык климатын яхшырту.

Сәнәгать паркларын үстерү мәшгульлек үсешенең төп резервы булып тора.

Районның Колаңгы ст. территориясендә «Кайбыч агропаркы» шәхси аккредитация узган сәнәгать паркы эшли. Сәнәгать паркында гомуми мәйданы 3,2

га, шулардан 0,9 га буш. 2 резидент эшчәнлеген алып бара: «СЛ-Молоко» ҖЧҖ, «СЛ-Агро» ҖЧҖ, анда 19 эш урыны булдырылган. Паркның тулылыгы 74% тәшкил итә. Эшчәнлегенең төп юнәлеше - чи сөт эшкәртү, сөт продуктларын җитештерү һәм сату, витаминлы-үлән оны ясау.

Хезмәт базары районның социаль-икътисадый үсешенең тотрыклылыгы һәм нәтиҗәлелеге турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә торган индикаторларның берсе булып тора.

Агымдагы ел башына эшсезләр саны 8 кеше тәшкил итте. Теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе - 0,12%. (ТР буенча - 0,16%).

2025 елның 1 ноябренә 11 эшсез граждан исәптә тора, эшсезлек дәрәҗәсе 0,17 % (ТР буенча 0,16 %). Шул ук вакытта бүгенге көндә район эш бирүчеләре тарафыннан 52 вакансия тәкъдим ителә.

Фаразлана торган елда Хезмәт һәм мәшгульлек министрлыгы тәкъдиме буенча 0,12-0,13% дәрәҗәсе билгеләнде. (ТР буенча 0,20%)

Хезмәткә сәләтле халыкның төп керем чыганагы булып элеккечә үк хезмәт хакы кала. Хезмәт хакы фонды фаразы предприятиеләр, бюджет учреждениеләренең фаразлана торган уртача хезмәт хакыннан чыгып исәпләнгән.

Уртача хезмәт хакы 2024 елның гыйнвар-декабрь айларында район буенча 55 329 сум тәшкил иткән. ( ТР буенча - 75 764 сум).

Агымдагы елның ахырына 12,6% үсеш белән 62 277 сум планлаштырылган.

Эре һәм урта предприятиеләр буенча факттагы күрсәткеч 2025 елның 8 аена 64 822 сум (үсеш темпы - 118%) тәшкил иткән (Татарстан Республикасы буенча - 84 886 сум). Шул исәптән авыл хуҗалыгы предприятиеләре буенча - 77 225 сум (үсеш темпы - 139 %). Чагыштыру өчен Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек җитештерүчеләренә 2025 елның 8 аенда - 67617 сум, үсеш 23 % тәшкил итә.

Алдагы өч елга үсеш темпы 106,8%; 105,2% һәм 105% дәрәҗәсендә фаразлана (ТР буенча 108,1%; 107,0% һәм 106,6%).

Хезмәт базарындагы киеренкелекне булдырмау максатларында ай саен Тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча ведомствоара комиссия, Легаль булмаган мәшгульлеккә каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия утырышлары уздырыла. Акцент хезмәт өчен түләүнең хезмәт хакының минималь күләменнән кимрәк булмавына һәм тармак буенча уртача республика дәрәҗәсенә җиткерүгә куела.

Алдагы өч ел прогнозының төп күрсәткечләре шундый.